**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**“ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ КАРАБАШ БИСТӘСЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**АЛТМЫШ БЕРЕНЧЕ СЕССИЯ**

**1нче КАРАР**

Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе «23» июль, 2019 ел

**Бөгелмә муниципаль районы**
**шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе Советының**
**2019 елның 20 маенда булып узган**
**58нче сессиясендә кабул ителгән**
**“Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы**
**“Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе” муниципаль берәмлегендә**
**гавами тыңлауларны оештыру**
**һәм уздыру тәртибе турында”гы нигезләмә турында”гы 4нче карарга**
**үзгәрешләр кертү турында**

Законнарга туры китерү максатында һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**“Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе”**
**муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАР БИРДЕ:**

Бөгелмә муниципаль районы “Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе” муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 20 маенда булып узган 58нче сессиясендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында”гы нигезләмә турында”гы 4нче карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 2нче бүлектә:
1.1. 2.2нче пунктның 1нче аспунктын яңа басмада бәян итәргә:
“1) “Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый-норматив акты проекты, муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр Россия Федерациясе Конституциясендәге, федераль законнардагы,

Россия Федерациясе субъекты Конституциясе (Уставы) яки законнарындагы нигезләмәләрне, шул хокукый-норматив актларга туры китереп, төгәл китерү формасындагы кертелү очракларыннан тыш”;

1.2. 2.2нче пунктның 3нче аспунктын яңа басмада бәян итәргә:

“3) муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы сораулар, – 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән №131-ФЗ Федераль законының 13нче маддәсенә ярашлы рәвештә, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен муниципаль берәмлек халкының тавыш бирү тәртибендә яки гражданнар җыенында белдергән ризалыгы кирәк булган очраклардан тыш.”.

3. Әлеге карар күмәк мәгълүмат чараларында рәсми төстә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**“Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе”**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **М.Т.Минхәйдәров**